# Әхмәтҗанов Мөҗәһит Заһит улы



Мөҗәһит Заһит улы Әхмәтҗанов 1950 нче елның 15 нче декабрендә Татарстанның Мөслим районы Түреш авылында крестьян гаиләсендә туган. Башлангыч белемне туган авылында, урта белемне Күбәк урта мәктәбендә алганнан соң, 1968 – 1973 нче елларда Казан дәүләт университетының тарих – филология факультетында укый.1973 – 1975 нче елларда армиядә - Ерак Көнчыгышта взвод командиры булып хезмәт итә. Хәрби хезмәтне тутырып кайткач, берникадәр вакыт Үрәзмәт урта мәктәбендә директор урынбасары булып эшләп ала, аннары 1982 нче елга кадәр район комсомол һәм партия комитетларында төрле җаваплы вазифалар башкара. 1982 – 1995 нче елларда ул Мөслим урта мәктәбе директоры хезмәтендә, аннан соң шул ук мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. 1986 елда сафка баскан Мөслим урта мәктәбен (хәзерге Мөслим лицее) төзүдә һәм аны эшләтеп җибәрүдә Мөҗәһит Заһитовичның өлеше бик зур. Ул эшләгән елларда мәктәп бик күп уңышларга ирешә.

Мөҗәһит Заһит улы мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен “Халык мәгарифе отличнигы”, 1996 нчы елда “Татарстан Республикасы мәктәпләренең атказанган укытучысы “ дигән исемнәргә лаек булды. 2007 нче елда ул “Россиянең иң яхшы кешеләре” энциклопедиясенә кертелде.

Әхмәтҗанов М.З. - балалар шагыйре буларак та зур танылу алган шәхес. Мәктәптә укыган чакта ук ул балалар матбугаты: “Яшь ленинчы”(хәзерге”Сабантуй”) газетасы һәм “Ялкын” журналы битләрендә шигырьләре белән катнаша башлый. Балалар өчен ул хәзер тугыз китап авторы(“Мин санарга өйрәнәм”, “Матур булыйк”, “Карга бураны”, “Очты, очты...” “Акыллыга сүз әйттем”, “Әнием канатлары”, “Зирәк булу кирәк”, “Батыр буласым килә”, “Иман нуры”). Барлык китаплары ике дистәдән

артык. “Очты, очты...” һәм “Акыллыга сүз әйттем” китаплары “Ел китабы” конкурсында икенче, бер китабы(“Җиләкле җәй” , 2016) өченче урынга лаек булды. 2007 нче елда “Рухият” фонды тарафыннан үткәрелгән “Балаларга бүләк” конкурсында Мөҗәһит Әхмәтҗанов профессиональ язучылар арасында лауреат исеме алды.

Мөҗәһит Әхмәтҗанов гарәп хәрефләрен өйрәнүчеләр өчен “Күңел нуры”, “Гарәп графикасы нигезендә элекке татар язуы” исемле уку әсбаблары, туган авылы Түреш турында тарихи очерк һәм Мөслим төбәгеннән чыккан каләм ияләре турында биографик белешмә, Мөслим районындагы фольклор ансамбльләре турында “Мөслимем җәүһәрләре”, Мөслим авылындагы мәчетләр, мәдрәсә, мәктәпләр тарихына багышланган “Кыңгыраулы мәктәп еллары” исемле китаплар авторы буларак та укучыларга билгеле. 2009 нчы елда “Рухият” фонды тарафыннан “Зирәк булу кирәк” исемле табышмаклар китабы дөнья күрде.2010 нчы елда Татарстан китап нәшриятында балалар өчен “Батыр буласым килә” исемле шигырьләр җыентыгы басылды. Бүгенге көндә Мөҗәһит Әхмәтҗановның 40 ка якын китабы дөнья күрде.

Мөҗәһит Әхмәтҗанов 2014 елда якташ фольклорчыбыз, язучы, мәгърифәтче, исеме татар энциклопедиясенә кергән әкиятче бабай Зариф Мөэминовның гарәп графикасы белән язылган “Маҗара” исемле китабын кириллицага күчерде. 2015 елда ул Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты. 2015 елда “Ихлас” нәшриятында Мөслимнең сугыш һәм тыл ветераннарына багышланган “Утлы еллар аша” исемле китап төзеп бастырды.2020 нче елда гына да якташ шагыйрьләребез - Тукай чордашлары Кәшиф һәм Әхсәншәех Кормашевларның, Зариф Мөэминовның шигырьләрен гарәп графикасыннан бүгенге имляга күчереп, китап рәвешендә укучыларга тәкъдим итте. Актив хәбәрче Ягъсуп Мортазинның “Тормыш мизгелләре” китабын әзерләп бастырды һәм аның Түреш авылына багышланган чираттагы “Авылдашлар” китабы дөнья күрде.Үз ихатасында музей булдырды. Бүгенге көндә ул фото һәм видеолардан клиплар ясау белән мавыга.